ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Карар**

**« 18 » август 2023 ел** **№ 14**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрын һәм схемасын раслау турында» Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 18 апрелендәге 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 №89-ФЗ (25.12.2018) Федераль законның 13.4 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыкларны (мәйданнарны) туплау һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 31.08.2018 № 1039 номерлы карары нигезендә, Арча районы прокуратурасының 21.12.2021 №02-08-2021/298 күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1.«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрын һәм схемасын раслау турында» Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 18 апрелендәге 30 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь

калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары реестрын 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары схемасын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда ТР, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт; ТР, Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 25 йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы А.И.Сафин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башкарма комитетының
2023 елның 18 августындагы
14 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру урыннары реестры


| N | ККК җыю урыннары (мәйданчыклары) булу турында мәгълүмат (адрес һәм (яисә) географик координаталар турында белешмәләр) | ККК туплау урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары турында мәгълүмат (файдаланыла торган өслек, мәйдан, урнаштырылган һәм урнаштыруга планлаштырыла торган контейнерлар һәм бункерлар саны турындагы белешмәләр, аларның күләме күрсәтелә) | ККК туплау урыннары (мәйданчыклары) милекчеләре турында мәгълүмат (ЮЛ өчен: ЕГРЮЛга тулы исем һәм ОГРН, адрес; ИП өчен: Ф.И.Аи., ОГРН ЕГРИП язмаларын, яшәү урыны буенча теркәлү адресын; ФЛ өчен: Ф.И.Аи., паспортның яисә шәхесне таныклаучы башка документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы, контакт мәгълүматлары) | Каты коммуналь калдыклар барлыкка килү чыганаклары турында мәгълүмат, алар ККК туплау урыннарында (мәйданчыкларда) төзелә (физик һәм юридик затларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда тиешле урыннарда (мәйданчыкларда) КККК туплау урыннары барлыкка килә торган бер яисә берничә капиталь төзелеш объекты, җирлек территориясе (территориясенең бер өлеше) турында белешмәләр) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Арча районы, Яңасала авылы, Клуб урамы, 29 йорт янында<br>55,985925<br>49,981637 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Яңасала авылы халкы - Клуб ур., 17 - 45 йорт<br>"Яңасала башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ |
| 2 | Арча районы, Яңасала авылы, Клуб урамы, 8 йорт каршында<br>55,987820<br>49,979460 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Яңасала авылы халкы- Мәктәп ур., Клуб ур., 1 - 16 йорт<br>«Үзәк-2» кибете. |
| 3 | Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 29 йорт янында<br><br>55,983851<br>49,979933 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Яңасала авылы халкы-Үзәк ур., 24 - 49 йорт;<br>Яшьләр ур., 14 - 21 йорт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 13 йорт янында<br>55,987216<br>49,976031 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Яңасала авылы халкы-Үзәк ур., 1 - 23 йорт;<br>Яңасала авылы халкы-Яшьләр ур., 1 - 13 йорт:<br>"Арча сәүдә идарәсе" ҖЧҖ кибете, Авыл мәдәният йорты, Яңасала ФАПы, Яңасала авыл җирлеге административ бинасы, "Яңасала балалар бакчасы" МБМУ |
| 5 | Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 8 йорт янында<br>56,014976<br>49,960602 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Каенсар авылы халкы- Урта ур., 1-17 йорт;<br>Каенсар авылы халкы -Түбән ур., 1-8 йорт;<br>"Арча сәүдә идарәсе" ҖЧҖ кибете;<br>Җирле мөселман дини оешмасы - Мәчет. |
| 6 | Арча районы, Каенсар авылы, Урта урам, 24 йорт янында<br>56,017552<br>49,960369 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Каенсар авылы халкы-Урта ур., 18-39 йорт<br>Каенсар авыл клубы. |
| 7 | Арча районы, Каенсар авылы, Югары урам, 8 йорт янында<br>56,015891<br>49,956571 | 2 контейнер 0,75 м3 | Яңасала авыл җирлеге МБ | Каенсар авылы халкы- Югары урам, 1 - 14 йорт;<br>Каенсар авылы халкы, Г.Гафиятуллин ур., 1 - 15 йорт. |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башкарма комитетының
2023 елның 18 августындагы
14 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыгын урнаштыру схемасы**

Яңасала авылы



Каенсар авылы

